РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы, ул. Пионерская, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл жирлеге
Советы

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы, Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karinalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

30.05.2023 ел № 8

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районыныц
«Кармалы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.
3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алганнан соң халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кармалы авыл җирлеге
башлыгы А.Д. Кубышкин

Кармалы авыл җирлеге Советының
2023 елның 30 маендагы
8 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының
«Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясының 3 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.».

2. «Муниципаль сайлаулар» 13 статьясында:
6 пунктның икенче абзацында «Җирлекнец сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга;
7 пунктта «һәм әлеге Устав белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. «Җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү» 14 статьясында:
4 пунктта «Җирлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясен,» сүзләре белән алыштырырга;
7 пунктта:
беренче җөмләдә «Җирлекнец сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга,
икенче җөмләдә «сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләре белән алыштырырга;
12 пунктта «Җирлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләре белән алыштырырга.

4. «Авыл торак пункты старостасы» 19.1 статьясында:
2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пункты старостасы авыл торак пункты гражданнары җыены тәкъдиме буенча аның составына әлеге авыл торак пункты керә торган җирлек Советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пункты старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшькә җиткән һәм милкендә әлеге авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

3 пунктны «муниципаль вазыйфаны» сүзләреннән соң «, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга;

4 пунктның 1 пунктчасына «муниципаль вазыйфаны» сүзләреннән соң «үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,» сүзләрен өстәргә.

5. «Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты статусы» 28 статьясында:

10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләре белән алыштырырга;

12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

6. «Яңа сайланган җирлек Советы эшен оештыру» 30 статьясында «Җирлек сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен«җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алыштырырга.

7. «Җирлек Советы компетенциясе» 31 статьясының 1 пунктындагы 16 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

8. «Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 38 статьясын түбәндәге эчтәлекле 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре җирлек Советы карары белән, җитди сәбәпләрсез җирлек Советының барлык утырышларында алты ай рәттән депутат булмаган очракта, вакытыннан алда туктатыла.».

9. «Җирлек башлыгын сайлау тәртибе» 40 статьясының 1 пунктында «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләре белән алыштырырга.

10. «Җирлек башлыгы статусы» 41 статьясында:

3 пунктның 2 пунктчасында:

«а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенә» сүзләре белән алыштырырга;

«б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы

сайлау комиссиясенә» сүзләре белән алыштырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

11. «Җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 44 статьясында 1 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1) «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясының 13 пункты нигезендә вазыйфасыннан азат ителү.

12. «Җирлекнең сайлау комиссиясе» 51 статьясы үз көчен югалткан дип танырга.

13. «Җирлек Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре» 56 статьясының 3 пунктында:

«һәм Җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

«бу органнарны» сүзләрен «бу органны» сүзләре белән алыштырырга.

14. «Җирлек башлыгын отставкага җибәрү» 61 статьясында тиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрентиешле килешләрдә «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алмаштырырга.

15. «Муниципаль хокукый актларны әзерләү» 65 статьясының 1 пунктында «һәм сайлау комиссияләре тарафыннан» сүзләрен«комиссия тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.